| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.03.2023 Казан ш. № 157-пр

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 27.04.2017 № 175-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Боерам:

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 27.04.2017 № 175-пр боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 27.11.2018 № 580-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Коррупциягә каршы экспертизага кергән актларның (актлар проектлары) исәбе әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән зат тарафыннан алып барыла.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада күрсәтелгән формада йомгаклама төзелә.»;

2.3 – 2.4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Коррупциягә каршы экспертиза Актлар алынуның бишенче көнендә җаваплы зат тарафыннан үткkәрелә.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе йомгаклама буларак формалаштырыла, ул әлеге Тәртипнең 1.4 пунктына туры китереп төзелә.

Актка коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре турында актны экспертиза юллаган затка йомгаклама төзелгәннән һәм имзаланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.»;

3.1 – 3.6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык актлары проектларына, шулай ук, Министрлык тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы актлары проектларына (алга таба – акт проекты) коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкның хокук идарәсенең җаваплы заты тарафыннан хокукый экспертиза үткәргәндә үткәрелә.

3.2. Акт проекты коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Министрлыкның структур бүлекчәсенең проектны әзерләү өчен җаваплы заты тарафыннан юллана.

3.3. Коррупциягә каршы экспертиза акт проекты алынгач җаваплы зат тарафыннан 5 көн эчендә үткәрелә.

3.4. Акт проектында коррупцион фактлар булса, коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе әлеге Тәртипнең 1.4 пунктына туры китереп төзелгән йомгаклама буларак формалаштырыла.

Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе йомгаклама төзелгән көнне Министрлыкның проектны юллаган структур бүлекчәгә тапшырыла.

3.5. Коррупциоген факторлар булса, Министрлыкның проектны әзерләгән структур бүлекчәсе, йомгакламаны алгач та өч көн эчендә проектны эшләп бетерә һәм кабатлап коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы затка юллый.

3.6. Коррупциягә каршы экспертиза, эшләнеп беткән проект алынганнан соң өч көн эчендә, әлеге Тәртипнең 3.4 һәм 3.5 пунктында каралган тәртиптә кабатлап үткәрелә.»;

4.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе » сүзләре белән алмаштырырга;

4.12 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе » сүзләре белән алмаштырырга;

1 нче кушымтаны көчен югалткан дип танырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 16.03.2023 № 157-пр боерыгы редакциясендә)

Форма

Коррупциягә каршы экспертиза йомгакламасы

______________________________________________________________________

(норматив хокукый акт реквизитлары яки норматив хокукый акт проекты атамасы)

______________________________________________________________

“Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 2009 елның 17 июлендәге № 172-ФЗ Федераль законга, “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге № 883 карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә, “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге № 96 Карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасына таянып, коррупциогенных факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатында коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

______________________________________________________________________

(норматив хокукый акт атамасы (норматив хокукый акт проекты)

Вариант 1:

Күрсәтелгән норматив хокукый актта коррупциоген факторлар табылмады.

Вариант 2:

Күрсәтелгән норматив хокукый актта (норматив хокукый акт проектында) коррупциоген факторлар ачыкланды *.

Ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү өчен түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

___________________________________________________________________________

(коррупциоген факторларны бетерү ысуллары күрсәтелә)

(экспертиза үткәрү өчен
җаваплы затның вазифа атамасы) (имза) (инициаллар, фамилия)

* Коррупциоген факторлар ачыкланган норматив хокукый акт (норматив хокукый акт проекты) нигезләмәләре чагыла, аның структур берәмлеге (кисәк, бүлек, статья, өлеш, пункт, подпункт, абзац) һәм туры килгән коррупциоген факторлар, “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге № 96 Карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасына сылтамалар күрсәтелә.».

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**